# ТӨШКЕ АШ



Шәһәрдән авылга, бабасы белән әбисе янына, кунакка кайткан Ринат бүген соң уянды. Бабасының иртән иртүк киткәндә, «Озак йоклыйсың икән, улым. Мин болынга печән чабарга киттем. Төшке ашта яныма килерсең» дигән сүзләрен дә малай әллә төшендә генә ишетте инде.

Шәһәрдә беркем дә таң тишегеннән сикереп тормый. Ринат та менә иртә уяныргга күнекмәгән. Авылга җәй саен кайтса да, беренче көннәрдә йокыдан торулары һәрвакыт шулай авыр була. Бигрәк тә өй бүрәнәләренә сеңгән нарат сагызы исе, алманыкы белән кушылып, борынны кытыклый-кытыклый, үпкәләргә агып кергәндә. Эх, авыл һавасы...

Ринат күзләрен ачты. Киерелде. Юрган астыннан һич кенә дә чыгасы килми иде әле аның. Өй алдында сөт сорап йөрүче мәченең мияулаганы, тавыкларның кытаклаган тавышлары ишетелә башлады. Малай янә киерелде. Юрганы идәнгә шуып төшсә дә, малайның мендәргә ябышып калган башы өскә күтәрелмәде.

Кинәт ишек шыгырдады, һәм ак яулыгын бөркәнгән, зәңгәр күлмәген кигән әбисе күренде.

— Уяндыңмы, бәбкәм? Әйдә, ашарга тор. Табынны әзерләп куйдым инде.

Ринат, әбисенең йомшак тавышын ишетүгә үк, караваттан сикереп тә торды, юынырга да чапты. Майлы коймакларны ашап, баллы чәй эчкәннән соң, әбисе тастымалга төрелгән кәстрүлне, ипи телемнәрен, чәй тутырылган термосны сумкага салып, оныгына тоттырды:

— Көне бик кыздыра, улым. Бабаң сусагандыр, ачыккандыр. Тизрәк йөрергә тырыш, яме!

Ринат аптырап ук калды. Ничә тапкыр авылга кайтканы булса да, аңа мондый җаваплы эш кушканнары юк иде. Малайның сөенече эченә сыймады. Ул, баскычтагы сандалиларын киеп, юлга чыгарга ашыкты.

Елга буена бик тиз төшеп тә җитте. Бабасы белән бергә аның бу юллардан йөргәне бар иде. Бүген исә ул үзе генә! Бабасын ничек кенә табарга соң? Аяк астында сикерешкән чикерткәләр дә аңа бу сорауны бирә сыман тоелды. Малай шунда бабасы чапкан печән покосының күрше авылга таба сузылып киткәнен күреп алды. Кибә дә башлаган икән. Покоска карап, бабасын табачак ул! Малай чикерткәләргә күз кысты да елга яры буйлап китте.

Шулай бара торгач, кинәт таллар арасыннан авыл эте Акбай килеп чыкты. Ринатның дусты ул. Малай, ак койрыклы, кара борынлы дустын күргән саен, тәмле әйберләр белән сыйлый иде.

Ринат, покоска утырып, сумкадан ризыкларны алды. Тастымалны сүтеп, кәстрүлне ачып караса, анда дөге боткасы икән. Эткә бераз ботка бирим дип, кәстрүлгә тотынган гына иде, Акбай малайның кул астына ук кереп китте. Кәстрүл үләнгә капланды.



Күз ачып йомганчы Ринат, кәстрүлне күтәреп, ботканың бер өлешен саклап кала алды. Акбай исә дөге боткасын тәмләп ашый башлаган иде инде. Аңа карап, малай: «Нишләргә? Өйгә кайтыргамы? Бабай бит бик ачыккандыр. Кояш әнә ничек кыздыра. Юк, мин кире кайтмыйм. Ботка аз булса да калды әле. Чәй дә бар», — дип уйлады.

Акбай үләндәге дөге боткасын ашап бетереп, Ринатның кулын ялады, «Борчылма! Рәхмәт сиңа!» дигәндәй өреп тә алды. Дустының шулкадәр сөенгәнен күреп, малайның да кәефе күтәрелде. Ул печән покосы буйлап алга атлады.

Көн эссе. Эх! Киемнәрне салып, салкын суда чума-чума йөзәсе иде. Бу уйларны хуплагандай, елгада балыклар да сикерештеләр. Бабасы белән елга яры буйлап йөргәндә, Ринат балыкларга ипи ашатырга ярата иде.

Малай, үзе дә сизмәстән, сумкасыннан берничә ипи телемен чыгарды да, ваклый-ваклый, су өстенә сипте. Балыкларга мондый күчтәнәч бик ошады: алар хәтта ныграк сикерешә башладылар. Кап-кара яр карлыгачы ипи кисәген эләктереп үк очып китте.

Ринат юлын дәвам итте. «Кайда соң бабай? Беркая күренми».